Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Ишле авылында гражданнар җыены КАРАРЫ

01 декабрь 2021 ел　　　　Яңа Ишле авылы　　　　№ 1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының "Яңа Ишле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Яңа Ишле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
01 декабрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советы 07.10.2009 ел, № 49/1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Хисап комиссиясенең 2021 елның 1 декабрендә узган тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлары нигезендә 2021 елның 1 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның нигезендә:
Тавыш бирү тәмамлануга гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 171 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 107, бу торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның 62,57% ын тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
«За» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 107 кеше тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның 100% ын тәшкил итә; «каршы» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде, бу 0% тәшкил итә.
Бәян ителгәннәр нигезендә карар кабул ителде:
1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Ишле торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 1 декабрендә узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.

2. "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Ишле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 2022 елда үзара салым кертүгә 1500 сум күләмендә акча һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:
- Яңа Ишле авылының Төньяк урамы буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;
- Яңа Ишле авылының Кооператив, Совет, Колхоз урамнары буенча юлларга вак таш салу;
- Яңа Ишле һәм Иске Чүпрәле авыллары арасында Пакерлы елгасы аша күпер ремонтлау» кабул ителгән.

3. 2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Ишле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешедән 1500

сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Яңа Ишле авылының Төньяк урамы буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Яңа Ишле авылының Кооператив, Совет, Колхоз урамнары буенча юлларга вак таш салу;

- Яңа Ишле һәм Иске Чүпрәле авыллары арасында Пакерлы елгасы аша күпер ремонтлау.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Ишле авылы, Совет урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов